# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлегенең Субаш торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 23 ноябре, Субаш авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 23 ноябрендә Айдар торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлегенең Субаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
- урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, эш өчен түләү;
- М. Җәлил, Ленин урамнары буенча юлларны грейдлау, юл буйларындагы үләнне чабу, урамнарны кардан чистарту, вак таш җәю (сатып алу, җәю, килешү буенча түләү);
- урам исемнәре, йорт номерлары күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру;
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 142 кеше кертелгән;
җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 99 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 99 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлегенең Субаш торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлегенең Субаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, эш өчен түләү;
- М. Җәлил, Ленин урамнары буенча юлларны грейдлау, юл буйларындагы үләнне чабу, урамнарны кардан чистарту, вак таш җәю (сатып алу, җәю, килешү буенча түләү);
- урам исемнәре, йорт номерлары күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру;
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру-кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Айдар авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Айдар авыл җирлеге Башлыгы: Р. Р. Хаҗиев